КАРАР
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче
Төбәк торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

24.08.2022 №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олы Кибәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карары нигезендә, 2023 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Төбәк авылы балалар һәм спорт мәйданчыгын төзекләндерү(чыгышлар өчен сәхнә ясау, элементларны буяу h.б) дигән сорау буенча 2022 нче елның 24 нче августында узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 175 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _90_ы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Кибәче авыл җирлегенең Төбәк торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2023 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Төбәк авылы балалар һәм спорт мәйданчыгын төзекләндерү(чыгышлар өчен сәхнә ясау, элементларны буяу h.б) дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче
Олы Кибәче авыл
җирлеге башлыгы А.К. Сафин